| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН СОВЕТ<br>ИСАКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 21 маендагы 89-2 номерлы

2011 елның 22 декабрендәге 1-20 номерлы Буа муниципаль районы
Исәк авыл җирлеге Советы карары белән расланган
«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Исәк авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы
Нигезләмәгә» үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2010 елның 8 маендагы 83-ФЗ номерлы «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, 2019 елның 27 декабрендәге 473-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» Федераль законга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль идарәне һәм муниципаль учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерү концепциясе турында» 2010 елның 4 июнендәге ПР-11-2 номерлы Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр Советы Президиумы карары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» ТР Законының 25 статьясы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставының 46-53 статьялары нигезендә, Исәк авыл Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге башкарма комитеты турында» гы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 5 бүлек, 4 абзацы, 4 пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм расларга :

«- муниципаль һәм шәхси торак фондының торак урыннары, Россия Федерациясе яки Россия Федерациясе субъекты милкендә булган күпфатирлы йортлардан тыш, авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортлардан тыш, билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип таныла;».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Исәк авыл җирлеге башлыгы З.Р.Мухаметзянова